**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**"18" сентябрь 2018 ел** **№ 72**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү һәм үткәрү турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Кама Тамагы районы Варварино авыл җирлеге Уставының 15 статьясы нигезендә, Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге башлыгының 2018 елның 04 сентябрендәге 05 номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары, Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советының 2018 елның 04 сентябрендәге 71 номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары нигезендә Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советы **карар кабул итте**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2018 елның 18 ноябренә җирле референдум билгеләргә.
2. 2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:
   "Сез 2019 елда Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, Армия сафында хезмәт итүче, 1-нче группа инвалидлардан тыш) 300 сум үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны киләсе эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:
   *** Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру:**
   - торак пунктлар эчендә чүп үләннәре чабу (җәйге-көзге чор) ;
   *** - җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**
   - торак пунктлар өчендә юлларны ремонтлау;

*** Җирләү урыннарын карап тору:**
- зиратларны чүп үләннәреннән чистарту;
*** Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**
-янгын гидрантларын (җайланмаларны) язгы-җәйге чорга һәм кышка әзерләү (шул исәптән кардан чистарту),аларга яктылык кайтаручы билгеләр урнаштыру.
-янгын сүндерү машинасын тәимин итү (шоферга хезмәт хакы түләү)
*** Каты көнкүреш калдыкларын җыю һәм ташу эшчәнлеген оештыру**
- каты көнкүреш калдыклары полигоннарын карап тоту һәм чистарту (шул исәптән чүп җыю һәм чыгару).

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерү:
1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Көрәле авылы, Үзәк ур., 2а;
2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Варварино авылы, Ленин урамы, 32;
шулай ук «Волжские зори» («Идел таннары») газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, «Идел таннары» район газетасының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Варварино авыл җирлеге Башлыгы Р.Т.Нотфуллинга йөкләргә.

“Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Варварино авыл җирлеге”
башлыгы, “Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы
Варварино авыл җирлеге”
Советы рәисе Р.Т.Нотфуллин